**СОВЕТ МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422602 с.Ташкирмень,
ул. Мира, д.40
тел: 8-(84378) -4-85-25
факс: 8-(84378) -4-85-25
e-mail: Makar.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАКАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422602 Ташкирмән авылы,
Тынычлык урамы, 40 нчы йорт
тел: 8-(84378) -4-85-25
факс: 8-(84378) -4-85-25
e-mail: Makar.La@tatar.ru

**2025 елның 24 декабре** **27 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 13 апрелендәге 67 номерлы Макаровка авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 декабрендәге 994 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 13 апрелендәге 67 номерлы Макаровка авыл җирлеге Советы карарына (18.10.2018 №79, 21.09.2020 №6, 25.10.2022 №125, 08.11.2022 №128/1, 23.01.2023 №149/1, 24.06.2024 №210, 11.11.2024 № 229, 30.04.2025 № 261 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге Советы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта «15 389» саннарын «16 928» саннары белән алыштырырга;

Күрсәтелгән карарның 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (кушымта)бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә туны муниципаль районның Макаровка авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Макаровка**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **С.М.Кашапов.**

Татарстан Республикасы муниципаль районының

Макаровка авыл җирлеге Советының 2018 елның
13 апрелендәге 67 номерлы карарына 1нче кушымта
*(ТатарстанРеспубликасмуниципаль районының
2025 елның 24 декабре 27 номерлы Макаровка
авыл җирлеге Советы карары редакциясендә*

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләрендә һәм шәһәр торак пунктларында | | | |
| | Тугызынчы төркем <*> | Унынчы төркем <*> | Унберенче төркем <*> | Уникенче төркем <*> |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 31 496 | 27 601 | 25 401 | 23 201 |

<*> Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлек кергән хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләмен билгеләү максатыннан тиешле муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына карап түбәндәге хезмәт хакы төркемнәре буенча бүленә:

1) шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә барлыкка килгән авыл һәм шәһәр торак пунктлары:
тугызынчы төркем 10 меңнән артык кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;
унынчы төркем - халык саны 5 меңнән 10 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;
унберенче төркем - 1,5 меңнән 5 меңгә кадәр кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;
уникенче - төркем халык саны 1,5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр.